ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111    Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 14

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

« 28 » 02 2024 ел.

Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә мәгълүматлар тапшыру тәртибенә 4 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Югары судының №3а-488/2022 эш буенча 2022 елның 4 октябрендәге карарын, Гомуми юрисдикциядәге дүртенче апелляция судының №66а-255/2023 эш буенча 2023 елның 1 мартындагы апелляция билгеләмәсен үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2022 елның 1 мартындагы 35 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2022 елның 29 августындагы 155 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә мәгълүматлар тапшыру тәртибенә 4 нче кушымтага үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу боерык 2023 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Юридик бүлек җитәкчесенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче А.В.Тыгин

4 нче кушымта (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 28._02_.2024 ел, № _14__ боерыгы редакциясендә)

20___ елның « 01 » _________________

капиталь ремонтка кертемнәр сыйфатында исәпләнгән, капиталь ремонт өчен кертемнәр сыйфатында күчкән акчалар, капиталь ремонт өчен махсус счеттан тотылган акчалар күләме турында, махсус счетта калган акчалар күләме турында, капиталь ремонт уздыруга займ һәм (яки) кредит шартнамәсе төзү турында белешмәләр

| Махсус счет хуҗасының оешту-хокук формасы (ТМШ/ТК/ИО) | Махсус счет хуҗасының тулы исеме | Махсус счет ачылган күпфатирлы йорт | Махсус счет номеры | Махсус счет ачылган кредит оешмасы (банк) исеме | Күпфатирлы йортның гомуми мәйданы, кв.м. | Күпфатирлы йортта торак биналарның гомуми мәйданы, кв.м. |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

| Капиталь ремонт фондына исәпләнгән акчалар һәм аларның капиталь ремонт фонды формалаша башлаудан (беренче исәпләүдән) хисап датасына кадәрге хәрәкәте турында мәгълүмат | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Исәпләнгән, сум. | | | Алынган, руб. | | | Капиталь ремонт өчен махсус счеттан тотылган чыгымнар, сум. | Махсус счетта калган акча**, сум. | Капиталь ремонт үткәрү өчен займ шартнамәсе һәм (яки) кредит шартнамәсе төзү турында белешмәләр |
| бина милекчеләренең кертемнәре | пенялар | барлыгы* (гр.8+гр.9) | бина милекчеләренең кертемнәре | капиталь ремонт фондына килгән башка төр керемнәр (РФ Торак кодексының 170 ст. 1 өлеше) | барлыгы* (гр.11+гр.12)* | | | |
| 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |

| Агымдагы ел башыннан хисап датасына кадәр капиталь ремонт фондына исәпләнгән акчалар һәм аларның хәрәкәте турында мәгълүмат | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ел башына калган акча, сум. | Исәпләнгән, сум. | | | Алынган, руб. | | | Капиталь ремонт өчен махсус счеттан капиталь ремонт өчен акча сарыф ителгән, сум. |
| | бина милекчеләренең кертемнәре | пенялар | барлыгы* (гр.18+гр.19) | бина милекчеләренең кертемнәре | капиталь ремонт фондына килгән башка төр керемнәр (РФ Торак кодексының 170 ст. 1 өлеше) | барлыгы* (гр.21+гр.22) | |
| 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 |

* Тиешле графаларның күрсәткечләр суммасы

** Мәгълүматлар актуаль, хисап кварталыннан соң килә торган айның 1 нче көненә (1 нче гыйнварга, 1 нче апрельгә, 1 нче июльгә, 1 нче октябрьгә) банкның расланган өземтәсе белән раслана.

Кулланылган кыскартулар исемлеге:
ТМШ – күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы торак милекчеләре ширкәте;
ТК – күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы торак кооперативы;
ИО – идарә итү шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы идарәче оешма.